ISSN 0868-4545



Салават күпере

И, Казан! дәртле Казан! моңлы Казан!

КАЗАН



...Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

Г.Тукай.



Казаным! Казаным!

Журналыбызның август һәм сентябрь саннары тулысынча Казан шәһәренә багышлана. Тиздән, тагын берничә елдан (2005 ел) Казаныбызга нигез салынуга Бер мең ел була.

P.S. Чагыштыру өчен: моннан берничә ел элек Мәскәү салынуга 850 ел билгеләп үтелгән иде.

«Казан» сүзе нәрсәне аңлата икән соң ул? Гомумән, нигә безнең шәһәребез «Казан» дип аталган? Бу хакта риваятьләр дә бар.

© "Салават күпере", 2001 ел




Казан Кремле. 1630нчы ел.

Жигули казак

Борын заманнарында Идел буйларында Жигули казак дигән юлбасар була. Аның кешеләре Болгарны талап, тәмам бөлдереп бетерәләр. Болгар шәһәре халкы бу юлбасардан туеп, яңа шәһәр урыны эзли һәм хәзерге Казан урынын яхшы дип таба. Ул урын елан оясы була. Шуннан кыш көне саламнар ташып, язын еланнарны ут төртеп яндыралар, һәм кала урыны чистарып кала.

Казан кайда корылган?

Элек-электән Болгар дәүләтенә төрле яулар һөҗүм итеп торганнар. Зур көрәшләр, сугышлар булган. Бу сугышларның күбесендә болгарлар җиңеп чыкканнар. Әмма көннәрдән бер көнне бик зур яу килеп, Болгар шәһәрен яндырган. Исән калган кешеләр Идел буйлап өскә таба менеп китәләр, яңа урын эзләп. Идел буйлап бик югары меналәр дә, сөйләшәләр: «Әйдә, суга йомычка салабыз. Йомычка кайда әйләнә, бөтерелә – шунда утырабыз», – диләр. Йомычка хәзерге Казан тирәсендә бөтерелә һәм, шунда кала корып, яши башлыйлар.



Казан. 1767 нче ел.

Казан кайнаган урын

Бер заманны хан кала корырга булган. «Кайда кала корыйк?» – дип кешеләре белән киңәшкән.

Берсе әйткән:

– Арбага казан куйыйк, казанга су салыйк, астына ут ягыйк, атларны чаптырып куйыйк. Казан кайда кайнап чыкса, шунда кала корырбыз, – дигән.

Шулай иткәннәр. Казан хәзерге Казан шәһәре урынында кайнап чыккан. Шуннан кала корганнар, ди.

Угым кая төшсә, каланы шунда салам

Мәми–Чаллы авылы янында Кала тавы бар. Ханнар шул тауда кала корганнар һәм шул тау башыннан ук ата торган булганнар. Бер хан ук атып әйткән: «Угым кая төшсә, каланы шунда күчереп салам», – дип.



Аның угы Казанның хәзерге хан мәчете тирәсенә төшкән. Укны шуннан барып табалар. Шуннан соң ук төшкән урынга эт күмәләр. Хан каланы шунда салырга куша. Каланы корып бетергәч, хан:

– Нигезгә нәрсә күмдегез?– ди.

– Эт күмдек, – диләр аңа.

– Кала этләргә кала икән алайса, – ди хан.

Бер заманны ханнар белән урыслар арасында тартыш була. Урыслар каланы ала алмый гаҗиз булалар. Шуннан урыслар бер мөселманга әйтәләр:

– Без сине алтынга күмәбез: каланы ничек алырга өйрәт, – диләр.

Бу кеше, акчага кызыгып, болай ди:

– Безнең мөселман намаз бозмый, сез иртәнге намаз вакытында килегез, алырсыз, — ди.

Шуннан урыслар, иртәнге намаз вакытында килеп, каланы алалар, мөселманнар намаз бозмыйлар. Хан тәрәзәдән кыйблага таба кош булып очып чыгып китә һәм Кабан күленә төшеп югала.







Минтимер Шәймиев,
Татарстан Җөмһүрияте Президенты

Казан ул Татарстан Республикасының баш шәһәре. Башкала дип тә йөртәләр аны.

Татарстан белән Президент идарә итә. Татарстанның Президенты – Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Казан баш кала булгач, Президентның эшләгән урыны да Казан шәһәрендә – Кремльдә урнашкан.

Кадерле балалар!

Тиздән, бик тиздән гүзәл мәркәзебез Казанның меңъеллыгын бәйрәм итәчәкбез. Әйе, шанлы, кодрәтле дәверләрдә дә, афәтле, гарасатлы чорларда да горурлыгын, мәгърурлыгын җуймаган Казаныбыз ошбу бәйрәм-тантанага мең мәртәбә лаек.

Гали дә, үтә гади дә, тыйнак һәм сабыр да, эшсөяр дә, шагыйрь дә, орышларда курку белмәс яугир дә булган борынгы бабаларыбыз Казанга нигез салганда изгедән изге теләкләр генә теләгәннәрдер: «Казан озын гомерле, бай тарихлы, тагын да гүзәл кала булсын!» дигәннәрдер.

Бүген Казаныбызга – мең яшь! Башкалабызның әйтеп-сөйләп бетергесез бай тарихы бар. Ул көннән-көн зурая, матурая, төзекләнә, ямьләнә. Аның тагын да күркәм, тагын да гүзәл, чиста-пөхтә шәһәр булуы сездән дә тора, кадерле балалар.



Президент Казан шәһәрендәге Кремльдә эшли дидек.

Казан Кремле бик борынгы корылма ул.

Кремль Казанның йөрәге, җаны да. Кремльсез Казанны күз алдына да китереп булмас иде.

Атаклы Сөембикә манарасы да нәкъ менә Кремль эчендә урнашкан. Әлеге манара хакында халык күңелендә төрле риваятьләр саклана. Чынлап та, әлеге биек манара нигә «Сөембикә» дип аталган соң?

Сөембикә

Бервакыт Мәскәү патшасы Сөембикәнең (ул Казан Ханбикәсе була) рәсемен күрә дә аңа гашыйк була. Илчеләрен җибәрә инде бу хәзер Казанга, Сөембикә янына, үзенә кияүгә чыгарга сорап. Сөембикә моңа риза булмый. Шуннан Мәскәү патшасы, ачуы килеп: «Үз теләгең белән чыкмасаң, мин сине сугышып алам!» – ди дә, Казан ханлыгына каршы сугыш ача. Җиде ел камап торганнан соң, крепость стеналарын ваттырып, Казан шәһәрен ала бу. Сөембикә дошманының җиңүен күргәч, ире күмелгән мәчетнең манарасына менә дә аска ташлана. Менә шуннан соң инде Хан мәчетен «Сөембикә манарасы» дип атый башлыйлар.





Казанның мэры, ягъни башлыгы
Камил Шамил улы Исхаков.



Кадерле балалар!

Тукай юкка гына «И Казан! Нурлы Казан!» дип язмагандыр. Әле ул вакытларда Казан алай ук нурлы булмаса да, шагыйрь башкаланы бик зурлаган.

Казан – бик тә борынгы шәһәр. Моннан мең ел элек нигез салынган булган аңа. Ул чакта хәтта Мәскәү шәһәре дә булмаган әле.

Бик зур бәхәсләрдән соң, бик күп хезмәтләр куйганнан соң, ниһаять, без Казаныбызга мең яшь икәнлеген раслый алдык!..

Хәзерге Казан – бөтенләй үзгә Казан. Ул чынлап та нурлы шәһәргә әйләнде. Өстәвенә шәһәребез һаман зурая бара. Чагыштырмача күптән түгел генә халык саны бер миллионга тулган иде, хәзер Казанда яшәүчеләрнең исәбе ике миллионга якынлашып килә.

Казанның көннән-көн матураюы барыбызның да күз алдында. Мин ышаныч белән шуны әйтә алам: сез зур егетләр, зур кызлар булып үсеп җиткәндә Казаныбыз тагын да гүзәлрәк, тагын да матуррак шәһәр булыр.



Казан. 1839 нчы ел.

Кремльгә сәяхәтне дәвам итәбез:

Казан Кремле – бик борынгы корылма. Кремль татарча «Кирмән» сүзеннән килеп чыккан, ул сүз «шәһәр» дигәнне аңлата.

1552 нче елда урыс кенәзе Андрей Курбский Кремль турында болай дип яза:

«Менә без Казанга якынлаштык: аның көнчыгышында Казансу елгасы ага, көнбатышында – Болак елгасы. Елга шәһәр эченнән үк ага, башланган урыны Кабан күленнән. Үтәргә кыен бу елганы аркылып чыккан очракта да күл белән шәһәр арасында Арча кыры ягыннан бик биек һәм текә тау бар. Шәһәр әйләнәсе буйлап Болак елгасыннан алып Черек күлгә чаклы тирән чокырлар казылган. Ә Казансу ягыннан исә тау тагын да биегрәк. Һәм нәкъ менә шул тау башында крепость һәм Хан сарае урнашкан, шунда ук биек таш мәчетләр бар. Хәтерем ялгышмаса, алар бишәү иде бугай. Казан ханы үзенең 30 меңлек гаскәре белән шул крепость эченә кереп бикләнгән».

Димәк, ул вакытта ук Кремль эченә 30 мең кеше сыя алган!

Үз тарихыңны яхшы бел, балам!

1552 нче елда урыслар Казанны басып ала. Аңарчы Казан ханлыгы азат, мөстәкыйль дәүләт була. Әмма караңгы октябрь көннәрендә Казан дәүләте үзенең бәйсезлеген югалта.

Урыслар патшасы Иван Грозный басып алганчы Казан бай һәм бик матур шәһәр була. Грозный кушуы буенча шәһәрдәге мәчетләр, зиратлар, бай китапханәләр җимертелә. Зиннәтле Хан сараен урыс гаскәрләре пычратып бетерә, аны корал складына әйләндерәләр.



Казан Кремле. XIX гасыр.

Казанны басып алгач урыслар шәһәрдә ике агач чиркәү (Киприн һәм Иустан чиркәүләре) салып куялар.

Без хәзер яшәгән Яңа Казанга кадәр безнең әле Иске Казаныбыз да булган. Хәзер ул урыннардан Арча тимер юлы уза. Ул хәзерге Камай станциясеннән ерак түгел.

Яңа Казан бик матур җирдә урнашкан. Көнбатышта хәзерге Кремль калкулыгы урнашкан итәктән үк Болак суы ага. Казансу (Казанка) исә әлеге калкулыкның төньягында. Болак та элек Казансуга аккан.



Казан Кремленең менә шундый сурәтен дә хәтерли тарих.



Кремль янында Казансу аша салынган күпер кайчандыр менә шундый булган.

Бу урында, Казансу ярында, ул заманда атаклы Таһир мунчасы булган. Ә Болакның икенче очы Кабан күлләренә барып тоташа. Бу күлләр Түбән Кабан, Урта Кабан, Ерак Кабан дип атала. Кремль калкулыгыннан көнбатышка таба, Болак суы аръягында, чакрымнарга сузылган яшел болыннар, зәңгәр күллекләр, әрәмәлекләр булган. Бу җирләр «Хан болыны» дип йөртелгән. Казан ханлыгы чорында Сабан туйлары да шушында уздырылган. Бу болынлыкта Казан халкы ял иткән, күңел ачкан, көч сынашкан, төрле ярышлар, хәрби уеннар оештырган. Болынлыкның Кабан күленә якынрак очында «Үтәч мәчете» булган. Иван Грозный гаскәрләре Казанны басып алганчы әүвәл нәкъ менә шунда тупланалар инде.

Горур кыяфәт белән тау башында басып торган зиннәтле сарайларны, биек манаралы матур мәчетләрне, бизәлеп эшләнгән биналарны читтән килгән һәр кеше исе китеп, сокланып караган. Хәтта каланы җимерергә дип килгән Явыз Иван да Казанның матурлыгына соклануын яшерә алмаган.





1889 нчы ел.

Казан ханлыгы чорында башкаланың үзәк өлеше биек һәм калын диварлар белән уратылып алынган була. Ул стеналар эченә ком, таш тутыралар. Дошман җимерә алмасын өчен ул стена–диварлар бик киң, нык итеп эшләнелә. Мәсәлән, Болак буйлап сузылган диварның киңлеге 6 метр тирәсе, Арча кырындагы стена калынлыгы 15 метр була. Стена–дивар каршына тирән чокырлар казылган, аларга су тутырганнар. Эчкә үтеп керү өчен күтәрмә күперләр, капкалар булган.

Исемнәре безнең көннәргә килеп җиткән 13 шәһәр капкасы билгеле. Мәсәлән, шуларның кайберләре: Түбән капкасы, Нургали капкасы, Алабуга (Илбуга) капкасы, Хан капкасы, Арча капкасы һәм башкалар.

Урыслар басып алганчы Казан Идел буеның иң гүзәл һәм зур шәһәрләреннән саналган. Ул бик тиз үскән, ныгыган, бай булган. Әмма бераздан соң көндәше Мәскәү аңа комсыз күзен кыздыра башлаган.



«Кытай» трактиры.



Пассаж.



«Толчок».



Хәзерге Чернышевский урамы.



Печән базары.



Ушаков йорты.

Казан шәһәренә болгар ханы Ибраһим нигез салган.

Хәзер Казанда 2 миллионга якын кеше яши.

1920нче елда Казан шәһәре Татарстанның башкаласы итеп игълан ителә. Шуннан соң шәһәрне тагын да матурайту, тергезү эшләре башланып китә. Казанда яшәүче халык саны да бик нык арта башлый. Ул зур сәнәгать (промышленность) үзәгенә әверелә. Шәһәрдә хәзер бит юа торган сабыннан алып куәтле вертолет һәм самолетларга кадәр эшләнелә.

Революциягә чаклы (1917 нче ел) Казан кварталларга бүленеп йөртелгән. Болак арты кварталында гадәттә татарлар яшәгән, бирге якта башка милләт халыклары күбрәк була. Шуннан соң районнар хасил була башлый. Әүвәл ике зур район төзелә, аннан соң дүрт, биш, 1973 нче елда районнар саны җидегә җитә.

Казанда хәзер Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Яңа-Савин, Мәскәү, Идел буе һәм Совет районнары бар.

Казандагы атаклы урам-мәйданнар.

Беренче май мәйданы.

Ул Кремль каршындагы мәйдан. Анда Дәүләт музее, М.Җәлил һәйкәле бар. Әлеге мәйданда шәһәр хакимияте бинасы да урнашкан. Революциягә кадәр анда шәһәр Думасы эшләгән.



Кремль урамы. Ул элек Ленин урамы дип йөртелә иде.

С.Хәкимнең: «Йөрим таңда Ленин урамында, күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән шигырен әти–әниләрегез яхшы хәтерли торгандыр әле. Революциягә чаклы әлеге урам «Большая проломная» урамы дип аталган. Урыс гаскәрләре Кремльне нәкъ менә шушы урам турысыннан шартлаталар һәм анда зур чокыр (пролом) хасил була.

Казанда Муса Җәлил, Кави Нәҗми, Кол Гали, Хәсән Туфан һәм башка атаклы язучылар исемендәге урамнар да бар.



Университет

Казан университеты дөньядагы иң борынгы һәм зур уку йортларыннан санала. Ул Рәсәйдә иң беренчеләрдән булып 1805 нче елда ачыла. Аның даны К. Насыйри, Х.Фәезханов, И.Хальдин, Н.Лобачевский, Х.Мөштәри, А.Арбузов кебек галимнәр аркасында тагын да үскән.



М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры.



Язучылар йорты.



Сынлы сәнгать музее.



Техник университет.



Г.Камал театры.



Тукай музее.



Казан Калабызның

Касыйм шәех

Кабанбәк

Кабан күле


Хикмәтле бишмәт

Күр әле син безнең калабызны. Казансуның Иделгә кушылган урыны нәкъ диңгез кебек. Ул күлләре, ул күлләре... Зәңгәр күл, Тирән күл, Аккош күле, Черек күл, Кабан... Ә су булган җирдә риваятьләр тумый калмый. Кабан күле турында гына да дистәләрчә риваять бар. Каюм Насыйри китергәне Касыйм шәех дигән изге карт белән бәйле. Ул бу урынга төпләнергә кешеләр алып килә. Тик берсенең дә казык кагарга күңеле тартмый. Тирә-якта – урман-чытырман, камышлы сазлыклар. Су юк. Әүвәл изге карт, утырып дога кыла, аннары бишмәтен сөйрәп китә. Бишмәт тиеп үткән җирдә күл хасил була.

Икенче риваятьтә сүз Болгар дәүләте тар-мар ителгәннән соң Аксак Тимер әзәрлекләвеннән качып килгән хан улы Кабанбәк турында бара. Ул күл суы белән юынып сихәтләнеп китә... Ул күл суы белән юынып сихәткөч ала. Тиздән монда мәһабәт сарай сала. Күлне исә хан улы хөрмәтенә «Кабан» дип йөртә башлыйлар.



Зәңгәр күзләре




Хәзинәне кем таба?

Кабан – бай күл. Риваятьләргә генә түгел, чын мәгънәсендә алтын-көмешкә бай күл ул. Әйе, әйе, аның төбендә хәзинә ята. Юклы-барлы мал түгел ул... Хан казнасы!.. Бу хакта язучы Рафаэль Мостафин «Кабан күле серләре» китабында бик тәфсилләп яза.

Безнең бурыч, дускай, синең белән бергә әнә шул хәзинәне табу. Ә аңа юл әлеге китапта күрсәтелә. Анда язылганнарга караганда, имеш, Болак агып чыккан җирдән ерак түгел басарга, аннары берничә ук атымы араны үтәргә кирәк. Үттек. Хәзер инде каршы ярга йөз төбәп, берничә дилбегә буе (аның озынлыгын чамалыйсыңдыр) араны йөзеп үтәргә. Хәзинә күлнең нәкъ шул турысында ята. Табышмакмы? Табышмак! Чиш әйдә. Үзеңнең башың җитмәсә, әти-әниеңнән ярдәм сора.

Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА.





Әкият!

Бар шундый гаҗәп бер ил. Анда олы-олы апалар, абыйлар рәхәтләнеп курчаклы уйныйлар. Курчаклары да гади генә түгел – бик серлеләр, тылсымлылар. Шулай булмыйни! Ул курчакларны баш рәссам Валентина Губская һәм рәссам Александр Губский махсус ясыйлар бит. Ә баш режиссер Илдус Зиннуров һәм режиссер Людмила Дьяченко артист абыйларны, апаларны курчак уйнарга өйрәтә. Ә-ә, артист дигәч аңлады-




Т.Миңнуллин. «Укытты бүре сабак».



Р.Корбан, З.Думави. «Ак күлмәктә – кара елан».



Н.Дәүли. «Җырлап узган җәй».



Зөлфәт. «Таңга – Чулпан, айга – Зөһрә».

гызмы инде? Әлбәттә, сүз сезнең яраткан театрыгыз – курчак театры турында бара. Бу серле илдә сезнең дә булганыгыз бар бит. Исегезгә төшерегез әле.

Казандагы курчак театрының «Әкият» дип аталуын беләсездер, шәт. Сезне генә түгел, әти-әниләрегезне, хәтта, әби-бабаларыгызны да кызыклы-маҗаралы әкиятләре белән сөендергән, шаккатырган, тәрбияләгән


Зөлфәт. «Ат өреккән шомлы төн».


Зөлфәт. «Гасырдан озын бу көн...».

театр ул. Әби-бабаларыгыз, диюгә, бер дә гаҗәпләнмәгез, үзләреннән сорап карагыз әле, ничәнче елда туганнар алар? Ә курчак театры инде 1934 нче елдан бирле эшли. Мин дә, нәкъ менә сезнең яшьтә булганда – башлангыч класста укыганда – авылыбызга курчак театры килгән иде. Бүгенгә кадәр ул спектакльнең исемен дә хәтерлим – «Энҗеле үрдәк». Бик серле, могҗизалы бу әкият гомергә күңелемә сеңеп калды.

Ерак-ерак авылларга, ерак-ерак илләргә йөреп, күпме сабыйны театр дигән серле дөньяга алып кергән «Әкият» шул ул! Шуңа күрә, татарлар һәм руслар гына түгел, АКШта, Германия, Франция, Болгария, Польша һәм башка илләрдә яшәүче балалар да белә безнең Казан дәүләт курчак театрын. Иң дәрәҗәле фестивальләр үзәге Канн шәһәрендә Р.Корбанның «Бардым күлгә, салдым кармак», Төркиянең Адан шәһәрендә Зөлфәтнең «Ат өреккән шомлы төн» спектакльләрен дә тамашачы зур кызыксыну белән кабул иткән.

Театр 1974 нче елдан бирле Бөтендөнья курчак театрларының (УНИМА) даими әгъзасы.

Шушы урында сездән бер зу-ур сөенче аласым килә. Тиздән театрның өр-яңа бинасы булачак! Аны башкалабызның нәкъ үзәгендә М.Вахитов һәйкәле янында төзергә җыеналар. «Бу – Казанның 1000 еллыгы уңаеннан, иң яшь тамашачыга бер бүләк», – ди театрның директоры Роза апагыз Яппарова.

Бүләк дигәннән... Тагын бер бүләк турында.
Курчак театрында иң күп спектакль караган баланы без үзе теләгән вакытта, үзе теләгән спектакльгә
2 урынлы чакыру билеты белән бүләкләргә булдык.
Үзегез караган спектакльләр турында безнең журналга язып җибәрегез.

Илсөяр Иксанова.





Ләбиб Лерон

Шүрәле килде Казанга

Рәссам
Фәрит Муллахмәт

Шалтмылтфильм

Хәйран калды барча халык –
Абзыйлар вә түтиләр:
– Күрәле, безнең Казанга
Шүрәле килгән! – диләр.

«Башкалага ара ерак», –
Диеп бер дә тормаган,
Арчадан килгән Шүрәле –
Кырлай хәтле Кырлайдан!



Казан урамнарын гиздe,
Трамвайга утырып.
Прәнник, туңдырма ашады
Авызларын тутырып.



Кабанкүлдә, Казансуда
Су коенып алды ул.
Бармак-кармаклары белән
Балык тота язды ул.



Шулай йөри-йөри торгач,
Циркка да керде ул.
Тамашаның да кәттәсен
Менә шунда күрде ул.



Аю бии, этләр җырлый,
Казлар тарантас йөртә...
Клоуннар сүзсез-нисез
Бар халыкны көлдертә.



Бер мәлне тамашачылар
Күрделәр Шүрәлене:
– Әй, Шүрәле, безләрнең дә
Күңелен күрәле бер !



Шүрәлегә җитә калды –
Аренага элдерде.
Залдагыларның барчасын
Кытыкламый көлдерде.



Цирктан соң зоопаркка,
Театрга барды ул.
«Шүрәле» балетын карап,
Бик тә хәйран калды ул.



Төнге Казанны сокланып,
Күзәтеп, карап йөрде.
Тукай, Җәлил һәйкәлләрен
Һәм Кремльне күрде.



Мин дә йөрдем Казан буйлап
Шүрәле белән бергә:
Тәмле-татлы чәкчәк белән
Чәй эчеп чыкты бездә.



Арчасына, Кырлаена
Кайтып китәр алдыннан
Сурәткә дә төштек әле
Кабан күле янында.



Казан, Казан...

Әдәбиятлы вә мәгърифәтле изге калам — башкалам...



1550 еллар...

Чит-ятлар, үз кавем-дошманнар Казаныбызга – гүзәл мәркәзебезгә яный: әледән-әле һөҗүм итеп торалар.

Сак, уяу булырга, сакланырга кирәк.


Дәһшәт-афәтне күрәселәр алда әле...





Казан халкы – мәгърифәтле халык. Унтугызынчы (XIX) гасырда ук безгә – милләтебезгә К.Насыйри, Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани кебек атаклы галимнәрне бирде.

Мәгърифәт һәрвакытта күңелләргә нур чәчәр...





Урысның бөек шагыйре А.С.Пушкин – татарның әдәбият-сәнгать мохитенә аеруча зур йогынты ясаган әдипләрнең берсе. Ул 1833 елның сентябрендә, Е.Пугачев восстаниясенә кагылышлы мәгълүматлар туплау өчен Казанга килә. 6 сентябрьдә ул профессор К.Ф.Фукс һәм аның хатыны, шагыйрә, әдәби салон хуҗабикәсе А.А.Фукс белән очраша.

Татар дөньясын тирәнтен өйрәнгән, күпсанлы хезмәтләр язган Фукс галиҗәнаплары өендә Пушкин яңа шигырьләрен укый...

«Җиктереп пар ат, Казанга киттем туп-туры карап,
Чаптыра атларны кучер суккалап та тарткалап...»

Мәшһүр Тукаебыз Казанга килүен «Пар ат» шигырендә шулай тасвирлый... Арча сабыен, Җаек үсмерен Казан дөньяны таң калдырырлык ир-егет вә шагыйрь итәчәк әле...

Рәссам **М.С.Златаустованың** курчак-сыннары.

А.Эшкинин фотосурәтләре.



Сихерче кыз

Иске Казан бик текә тауда урнашкан булган, шуңа күрә Казансу елгасына төшү бик авыр икән. Ниндидер патша заманында бер кыз, Казансудан су алып менгәндә, арып, тауның уртасында туктаган да шәһәргә начар урын сайлаган өчен патша галиҗәнапларына ачу белдергән. Шушы вакытта гади кеше киеменнән йөрергә чыккан патша бу гүзәлнең зарын ишеткән дә, чыннан да, шәһәрнең урыны, бигрәк тә суга йөрү өчен, җайсыз икәнен әйткән. «Әйбәт урын кайда бар соң?» – дип тә сораган. Шуннан кыз Казанның хәзерге урынын әйткән.

– Син күрсәткән урын чыннан да шәп, – дигән патша, – әмма анда куркыныч еланнар оялаган.

– Алар, әфәндем, шәһәр төзүгә комачаулый алмый. Мин сихри көчкә ия. Әгәр әмер бирсәң, аларны кырып бетерә алам. Ә син урманны кисәргә һәм шәһәр корырга куш.

Патша кызның киңәшен тыңлаган һәм аңа еланнарны бетерергә кушкан. Кыз хәзерге Казан урынына барып, берничә урынга чокыр казыткан, салам, чыбык-чабык әзерләткән. Бөтенесе әзер булгач, ул берничә сихерле сүз әйткән. Еланнар ояларыннан чыгып, аңа таба шуыша башлаганнар. Кыз аларның бөтенесен өяргә һәм чокырларга салырга кушкан да саламны яндырып җибәргән. Шулай итеп, барлык еланнар кырылып беткән. Тик берсе, унике башлы очар елан, коточкыч тавыш чыгарып, һавага күтәрелгән. Әмма ул да ут көйдергән булганга, Казаннан унике чакрым җирдәге бер авыл янына егылып төшкән.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ.





Сер сандыгын сез ачасы...

Бер малайны беләм мин. Гадел атлы. Тарихны бик ярата. Киләчәктә археолог булмакчы. Тик менә әле күптән түгел генә Казан Кремлен ЮНЕСКО халыкара оешмасы канаты астына алыну уңае белән үткән б-и-и-к зур җыеннан борынын салындырып кайткан.

– Без үскәч тә ачарга сер калмый, – ди, кайгыра.

Алып киттем мин моны Казан Кремленә. Таныштырдым Татарстан археологларының атасы Фаяз Хуҗин абыйлары белән. Олуг галим әле яңа гына табылган бик-бик борынгы хан сарае нигезләрендә казу эшләре белән мәшгуль иде. Малайның, без үскәч, кызык бетә, дигәнен ишеткәч, и кычкырып та көлде соң!..

– Бар булган серне сез ачасы шул, – диде ул аннары. – Менә бу нигездәге хан сарае ни рәвешле булган, йә, әйт әле? Син зур үскәч тә, хикмәти приборлар, компьютерлар ярдәмендә моны модельләштереп, серен ачып куярсыз. Геофизика фәне ярдәмгә килер үзегезгә. Яңа ачышлар күплегеннән башларыгыз әйләнеп бетәр әле. Мең еллык башкала серләренә без әле яңа гына төшенә башладык ич. Ә беләмсең, Гадел, Кремль астында, бик-бик тирәндә, әллә ниткән яшерен җир асты юллары бар. Кулъязмалар шуны дәлилли. Әлегә хәтле берсе дә табылмаган көе. Ханнарның тиңсез хәзинәләрен, китапханәсен 1552 елда, Явыз Иван чирүе илебезгә яу булып килгәч, шушыннан алып чыкканнар бит. Кайда хәзер алар? Бәлки, шунында ук, аяк астында ятадыр, нәкъ менә син төшеп җиткәнне көтәләрдер? Бәлки, синең оныклар дәү булып, Кешелек Олуг Акыл Иясе булгач кына эзләп табарлык итеп яшерелгәндер алар, ә?





Нәни дуска мин дә бик күп сер чиштем. Әйтик, Казансу елгасы буенда таш, бронза гасырында, әле безнең эрага кадәр үк, гомер кичергән ерак бабайларыбызның торган урыннары табылды. Бусы тагын Гаделләр буынына өйрәнергә кала инде. Компрессор заводы белән Ял паркы арасында, Казансу буенда, тимер гасырына (б.э.к. VII-V гасырлар) караган Ананьино кабиләләренең тору урыннары, крепостьлар да яңадан-яңа ачыш булып, сер сандыгын ачканнарын көтә. Кабан күле янында ханнарыбызның илчеләр кабул итә торган җәйге резиденцияләре, крепостьлары (XII- XV гасырлар) урыны чират көтә. Бездә бит хәзер нибары 20археолог бар. Ә археология истәлекләре саны – 5 мең. Әлегә шуның 100енә кул тигән. Казан Кремле 12 гектар мәйдан биләсә, шуның нибары яртысында гына казу эшләре алып барылган. Әле мондагы серләр, беләсезме, күпме? Нәкъ иксез-чиксез галәм хәтле!

Ренат Гаффар.





Сәлават күпере

8-9(138-139) — 2001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТ, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛАР ЭШЛӘРЕ һӘМ МАССАКУЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Светлана ИБРАҺИМОВА рәсеме,

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тасләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 20.6.2001 ел.
Басарга кул куелды 20.6.2001 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 13369 данә. Заказ А-297.
Бәясе килешү буенча.

POINT

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

